| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **ГЛАВА СТАРОЧЕЛНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ИСКЕ ЧАЛЛЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ** |
| 423004, с. Старые Челны, ул. Ленина, дом 6, телефон:8(843)45-3-55-73 | 423004, Иске Чаллы авылы, Ленина ур., 6 йорт, телефон:8(843)45-3-55-73 |

ОГРН 1021605352449,ОКПО 04312558, ОКАТО 92246876000,
ИНН/ КПП 1632001610/163201001,ОКТМО 92646476

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Иске Чаллы **ав.** **КАРАР**

**«20» октябрь 2025 ел** **№ 4**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Урта Чаллы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына нигезләнеп, Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2025 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Урта Чаллы авылы, Карл Маркс урамы, 12нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Урта Чаллы авылы Карл Маркс урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2025 елның 12 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Урта Чаллы авылы, Карл Маркс ур., 12нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Урта Чаллы авылы Ф.Энгельс, Ленин һәм Яшьләр урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Урта Чаллы торак пунктында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын оештыру һәм уздыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлегенең Урта Чаллы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, балачак инвалидларыннан, 1 гр инвалидлардан, тыш, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толлары, СВОда катнашучылардан кала 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- урамнарны яктырту җайланмасы

«РИЗА» «КАРШЫ» ».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Чаллы авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы Т.В. Савинова